**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР
от ___________

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ __________

Актаныш муниципаль районының мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында карау, тәрбияләү һәм туклану өчен махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларын түләүдән азат итү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләсенең һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләсенең мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Актаныш муниципаль районы белем бирү оешмаларында балаларны карау, тәрбияләү һәм туклану өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итәргә.

2. Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмасына чираттан тыш кабул итү хокукы бирергә;

3. муниципаль белем бирү оешмаларында 1-11 нче сыйныфларда белем алучыларны ике тапкыр түләүсез кайнар ризык (1 нче иртәнге, 2 нче иртәнге аш) белән тәэмин итәргә;

4. Гомуми белем бирү оешмаларында озайтылган көн төркеменә йөрүче балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итәргә;

5. Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә һәм гомуми белем бирү оешмалары базасында эшләүче өстәмә белем бирү түгәрәкләрендә һәм секцияләрендә түгәрәкләргә һәм секцияләргә бушлай йөрүне тәэмин итәргә.

6. Югарыда күрсәтелгән ташламалар, туендыручысын югалткан очракта, мобилизацияләнгән гаиләдә яшәүче башка никахтагы балаларга да кагыла.

7. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ:

7.1. хәрби комиссариатның белем бирү оешмасында укучы тәрбияләнүченең ата-анасын (законлы вәкилен) чакырылу турындагы белешмәсе нигезендә, 1-5 пунктларында күрсәтелгән ташламалар белән тәэмин итәргә.

7.2. махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар кайтарылган очракта ташламаның гамәлдә булуын туктатуны контрольдә тоту максатыннан хәрби комиссариат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тотарга.

8. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләреннән белем алучы тәрбияләнүчеләрне Актаныш муниципаль районының мәгариф оешмаларында тоту һәм туклануны финанслауны тәэмин итәргә.

9. Әлеге карарның гамәлдә булуы гражданның хәрби хезмәт узу вакытына 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

10. «Актаныш муниципаль районының мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында карау, тәрбияләү һәм туклану өчен түләүдән өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын азат итү турында» 2022 елның 10 октябрендәге ПР-207 номерлы карары, 2022 елның 18 ноябрендәге «Актаныш муниципаль районының мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында карау, тәрбияләү һәм туклану өчен түләүдән өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын азат итү турында» 2022 елның 10 октябрендәге ПР-207 номерлы Башкарма комитет җитәкчесе карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» ПР - 240 номерлы карарын 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

11. Карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

12. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Ильясов